12+
DARELFONUN
УНИВЕРСИТЕТ
Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы 16 февраль, 2017 ел № 2 (155)




Елена Гредюшко фотосы

# Безнекеләр беренче!

«Шәхес» рубрикасының бүгенге кунагы – безнең штаттан тыш хәбәрчебез, «Ел студенты – 2016» республикакүләм бәйгедә «Ел журналисты» исеменә лаек булучы кыз, КФУның татар журналистикасы кафедрасы студенты Регина Шиһабетдинова. Бәйгедә тапшырылган юллама буенча, шушы көннәрдә ул Санкт-Петербург шәһәренә сәяхәткә китәчәк. Аны чын күңелдән котлыйбыз һәм газета өчен кызыклы материал көтеп калабыз!

## ЛОБАЧЕВСКИЙ ЕЛЫ

КФУда ректор **И.Гафуров** лекциясе белән Казан университетын төзегән һәм житәкләгән олы шәхес – Лобачевский елы рәсми рәвештә башланды. 2017 елда Математик белем бирү үзәген ачу, берничә зур конференция һәм форум, традицион Лобачевский укулары һәм студентлар арасында математик олимпиада үткәрү каралган.

## МЕДИЦИНА БЕЛЕМЕ

13 февраль көнне КФУның Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе базасында урнашкан шоу-румда медицина белеме сыйфаты турында сөйләштеләр. Ток-шоу спикерлары арасында КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры **А.Киясов**, «Казан» клиникасы баш табибы **А.Абашев** һәм КФУның җәмәгатьчелек белән элемтә буенча ректор киңәшчесе **Ю.Алаев** булды.

## МИН КАБАТТАН САЙЛЫЙМ

Бердәм тавыш бирү көнендә студентлар **«Мин кабаттан сайлыйм»** акциясендә катнаша ала. Проектны студентлар профсоюз комитеты оештыра. «Әгәр яңадан сайлау мөмкинлеге булса, сез КФУга укырга керер идегезме?» дигән сорауга җавап бирергә кирәк булачак. 21нче февральдә сайлау урналары КФУның барлык биналарында урнаштырылачак. Тавыш бирү 9:00 алып 18:00 кадәр. Акция укыту процессында чагылыш тапкан уңыш һәм кимчелекләрне билгеләргә мөмкинлек бирәчәк.

# БИЛГЕСЕЗ ЛОБАЧЕВСКИЙ

Казан гимназиясенең кырыс шартларында 5 ел укыганнан соң, тыныч холык белән аерылып тормаган Николай Лобачевский Казан университетында үзен «иректә» итеп тоя. Университетта тәртип кырыс булуга карамастан, студентлар гимназистларга караганда мөстәкыйльрәк була. Лобачевскийның гаеп эшләре шактый күп була, мәсәлән, университет директоры булышчысы Кондырев 33 тапкыр кондуит журналга Николайның шуклыкларын терки. Нинди ярамаган эшләр соң бу һәм 19 гасыр башында студент өчен ни белән тәмамлана ала?

Студент буларак, Николай Лобачевский төрле курслар өйрәнә. Алар арасында фәлсәфә, тарих, география, статистика, грек һәм латин телләре, рәсәй сүз иҗаты, арифметика, алгебра, геометрия, дифференциаль, интеграль һәм вариацион исәпләүләр, аналитик геометрия, механика, статика, аэростатика, гидростатика, гидравлика, физика, химия, технология, табигый, сәяси һәм халыкара хокук була. Әлеге фәннәр җыелмасын һәм күләмен күз алдына китерүе дә кыен. Лобачевский чынлап та барысына да өлгерә!

Казан университетын тәмамлаган М.П.Веселовский хатирәләрендә Лобачевскийның мондый шуклыгы сурәтләнгән: бервакыт, чираттагы бәйрәмнән соң, Николай университетка сыерга атланып килә. Перцов хатирәләрендә болай диелә: бервакыт Лобачевский, күңелле компаниядә бәхәскә кереп, усал профессор Никольскийның башы аша сикерергә вәгъдә бирә һәм моны чыннан да үти. Мондый шуклыклар җитәкчеләрнең ачуын чыгара, әмма Николай өчен күңелсез нәтиҗәләргә китерми.

Беренче җитди җәзаны Лобачевский 1808 нче елның җәендә ала…

***Дәвамы булачак…***

*Мәгълүмат kpfu.ru сайтыннан алынды*



Айгөл Абдрахманова фотосы

# СТУДЕНТ-УКЫТУЧЫЛАР

**Раил САДРЕТДИНОВ**

2016 ЕЛДАН БАШЛАП, МӘКТӘП УКЫТУЧЫЛАРЫ ӨЧЕН КФУНЫҢ Л.ТОЛСТОЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ ТАТАРИСТИКА ҺӘМ ТЮРКОЛОГИЯ ЮГАРЫ МӘКТӘБЕ БАЗАСЫНДА ҮТКЕРЕЛӘ ТОРГАН КВАЛИФИКАЦИЯ КҮТӘРҮ КУРСЛАРЫНДА ВАКЫТ МАШИНАСЫ УЙЛАП ТАПКАННАР.

Кайчандыр университетыбызда педагогика юнәлешен тәмамлаган, бүген республикабыз мәктәпләрендә эшләүче тәҗрибәле укытучылар аның ярдәмендә 3 атнага кабат студент булды, үзләренең яраткан остазларыннан дәрес алу бәхетенә иреште.

КФУ квалификация күтәрү курсларын Мәгариф министрлыгы грантын отканнан соң оештыра башлый. Студент-укытучыларга куелган таләпләр бик җитди — 3 атна дәвамында 5әр көн иртәдән алып кичкә кадәр укуда. Бер көн дә дәрес калдырырга ярамый. Курслар беткәннән соң, татар теле һәм әдәбиятын укыту юнәлешендә проект якларга тиеш булалар.

*— Әлеге курслардан укытучылар укыту алымнарын төрләндереп, нәрсәнедер тулыландырып кайтып китәләр. Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартлары шартларында дәресләргә нинди яңалык кертеп, нинди алымнарны үзгәртеп була дигән сорауга җавап эзлиләр, күп белем туплыйлар. Чөнки аларны әзерлекле вуз укытучылары укыта. Бер яктан, аларның кайберләре мәктәпне белми, әмма теоретик базаны төзүчеләр — вуз укытучылары. Гамәли мәктәп укытучылары шул белемнәрне тирәнәйтәләр, фәндәге яңалыкларны алып кайтып китәләр. Яңалык белән коралланган укытучының дәресе дә сыйфатлырак булырга тиеш,* — дип саный КФУның Татаристика һәм төркология югары мәктәбе доценты, курс җитәкчеләренең берсе **Әлфия Мотыйгуллина**.

Тәҗрибә уртаклашу мәйданы итеп башкалабыз мәктәпләре сайланган. Курсларга килгән укытучылар белән без, «Darelfөnүn» газетасы хезмәткәрләре дә, Совет районындагы 111 нче мәктәптә очраштык. Әлеге мәктәп үзе дә, укучылары да безгә яхшы таныш. Укытучыларга һәм укучыларга без журналистика буенча осталык дәресе күрсәттек. Безнең белән очрашудан соң, үзләренең дә күп кенә яңалыклары җыелган булып чыкты. Әле яңа гына татарча сөйләшә башлаган «Фиксики» мультфильмына тавыш яздыруда, татар теле буенча үткәрелгән олимпиадада, дзюдо ярышларында катнашып та җиңүгә ирешүләре ачыкланды. Укучыларның сайт өчен язмалар әзерләгәндә килеп туган сорауларына җавап биргәннән соң, үзләре арасыннан бер «йолдызны» сайлап алып, пресс-конференция оештырдык. Төп рольне яшь җырчы, төрле иҗади конкурслар җиңүчесе, ТНВ каналында «Кичке аш» тапшыруын алып баручы, татарча «фиксиләр»не сөйләштергән укучы **Энҗе Әхмәтҗанова** башкарды. Уенга, укучылардан тыш, стажировка үтәргә килгән, балаларны тыйнак кына күзәтеп

утырган укытучылар да бик тиз кереп киттеләр, укучыларны уздыра-уздыра Энҗегә сорауларын яудыра башладылар.

Без күрсәткән осталык дәресе күп кенә укытучыларны кызыксындырды. Татар теле дәресләрендә куллану өчен, яңа алым ачтыгыз, диючеләр дә булды. Дәрестән соң кайбер укытучыларның КФУда оештырылган курслар турындагы фикерләрен белештек.

Азнакай районы Җиңү бистәсе мәктәбеннән татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Миләүшә Шәйхуллова**: Кайтуга ук, «Маяк» газетасы белән очрашу үткәрәчәкбез. Бигрәк тә балалар белән бер булып уйнау, интервью алу үрнәге ошады. Элек укучыларымның язмалары матбугатта еш басыла иде. Бу эшне торгызырга кирәк, дигән фикергә килдем.

Азнакай районы Кәкре Елга мәктәбеннән татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Илсөяр Сабирова**: Студент елларында яшәгән тулай торак янынннан (Гвардия ур., 35) үткәндә, шуннан яшьлек елларым йөгереп чыгар төсле, андагы 435 нче бүлмә һаман безне сагына кебек. Безне укыткан укытучылар белән очрашу күңелле булды, ләкин аларның күбесе юк инде.

Казан шәһәре Совет районы 175 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы **Әлфия Мостафина**: Курслар, иң беренче чиратта, бик эчтәлекле, файдалы. Безне кызыксындырган, без күрергә, ишетергә теләгән материалларны бирәләр. Вуз укытучыларының туганнарыдай якын итеп караулары, безнең хәлгә керә белүләре, безне ишетүләре куандырды.

Балтач районы Балтач гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучылары **Чулпан Гаптелганиева** һәм **Рәйсә Әхмәтова**: Онытылган әйберләрне кабат хәтердә яңарттык. Ләкин иң кыйммәтлесе — тәҗрибә алмашу. Журналистлар белән матур аралашу, күзгә-күз очрашу бик җылы, тәэсирле булды.

***P.S.*** *Балтач укытучылары «Дарелфөнүн» редакциясен үзләренә кунакка чакырды.*

---

# ГАЛИМ БУЛЫП ТУАЛАРМЫ, ӘЛЛӘ БУЛАЛАРМЫ?

**БУ СОРАУГА ҖАВАПНЫ ТАБУЫ БИК КЫЕН, АНЫ ҺӘРКЕМ ҮЗЕНЧӘ АҢЛЫЙ. БЕРӘҮЛӘР: «ЮК, ТУМЫЙЛАР, БУЛАЛАР», – ДИ, ИКЕНЧЕЛӘРЕ: «ДАҺИ БУЛЫП ТУАЛАР, БАР НӘРСӘ НӘСЕЛДӘН БИРЕЛӘ», – ДИГӘН ФИКЕРДӘ. «БЕР ПРОЦЕНТ ТАЛАНТТАН, 99ы – ХЕЗМӘТТӘН», – ДИП УЙЛАУЧЫЛАР ДА БАР. ГАДИ ГЕНӘ ӘЙТКӘНДӘ, АКЫЛЛЫ КЕШЕЛӘРДӘН СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР ТУА, АЛАР, ГЫЙЛЕМ ТУПЛАП, ГАЛИМ БУЛА, ӘММА БАРЫСЫ ДА ТҮГЕЛ, БИЛГЕЛЕ.**

**Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ, Рәмис НАСЫЙБУЛЛОВ**



Бүгенге көнебезне галимнәрсез күз алдына да китерә алмыйбыз, чөнки, таң аткан саен, Җир шарында яңа алым-ысуллар тумый икән, бер генә өлкә дә үсә алмаячак. Һәм, әлбәттә, бу очракта мәгарифнең яшь буынны укыту-тәрбияләү өлкәсе аерым игътибарга лаек. Укытучы булу — гомерлеккә белем илендә яшәп калу дигән сүз. Анда яшәү өчен исә, гаять зур түземлелек, эш сөючәнлек, пөхтәлек, җыйнаклык һәм тагын бик күп шундый сыйфатларга ия булу таләп ителә. Бәлки шуңа күрәдер дә, укытучы булып туарга кирәк, дип әйтә халык. Димәк, мондый олуг исемгә лаек булу өчен, күп укырга, педагогик осталыгыңны даими арттырырга, камилләштерергә кирәк. Һәм, әлбәттә, яшьләрне ярату, алар белән аралашудан тәм табу, бөтен гомереңне шул изге эшкә багышлау зарур. Бүген сүзебез әнә шул сыйфатларга ия булган психология һәм мәгариф институтының яшь галиме, педагогика фәннәре кандидаты **Илнар Фәһим улы Яруллин** хакында. Ул, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт педагогика университетының математика факультетына укырга керә. Аны уңышлы тәмамлап, аспирантурада белем ала. Бүгенге көндә ул укыту һәм тәрбияләү методологиясе кафедрасында хезмәт куя. Фәнни журналларда, шулай ук чит илләрдә мәкаләләрен даими рәвештә бастырып чыгара, конференцияләрдә катнаша.

Университетта укыту дәверендә Илнар Фәһим улы студентлар белән эшләүнең үз алымнарын булдырган. Студентлар материалны ятлап вакыт уздырмасын, ә укытучы сөйләгәннәрне аңнарына сеңдереп барсын, фәннең асылын аңласын иде дигән фикердә ул.

Яңа технологияләр кулланып, заманча дәресләр үткәргәне, студент тормышында булган проблемаларны аңлап эш итүе өчен, университетта аны бик ихтирам итәләр. Фәнни эшчәнлеге өчен университет җитәкчелегенең, Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамоталары белән күп тапкырлар бүләкләнде.

Гыйнвар азагында психология һәм мәгариф институтының гыйльми шурасы карары нигезендә Илнар Фәһим улы Яруллин укыту һәм тәрбияләү методологиясе кафедрасы доценты итеп сайланды. Киләчәктә дә яшь галим яңадан-яңа уңышларга ирешсен, милләтебез горурланырдай шәхес булсын иде. Яңа вазифасында уңышлар аңа!



# ЮРИДИК ФӘННЕҢ АСЫЛЫ

**Раил САДРЕТДИНОВ**

8 НЧЕ ФЕВРАЛЬ – КАЛЕНДАРЬДА РОССИЯ ФӘНЕ КӨНЕ БУЛАРАК ТЕРКӘЛГӘН. 1724 ЕЛНЫ НӘКЪ ШУШЫ КӨНДӘ ПЕТР I УКАЗЫ НИГЕЗЕНДӘ РОССИЯДӘ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ БАРЛЫККА КИЛӘ.

Фән дигәндә, күз алдына зур күзлекле, ак халатлы, башы бераз гына пеләшләнә башлаган профессор килеп баса. Фән кешеләрен күбрәк техник юнәлештә генә эшлиләр, алар, һәрчак үз-үзләренә бикләнеп, ниндидер ачышлар белән «җенләнеп» яшиләр дип беләбез. Ә менә бүгенге әңгәмәдәшем гуманитар өлкәдә дә мөһим фәнни тикшеренүләр, ачышлар ясала дип, әлеге стереотипларны төптән үк җимерде. Яшь, чибәр туташ – Казан федераль университеты юридик факультетының студентлар фәнни җәмгыяте җитәкчесе урынбасары **Лилия Яфизова** (*фотода уңнан дүртенче*).

Казан федераль университеты юридик факультетының студентлар фәнни җәмгыяте 2004 елдан бирле юриспруденция өлкәсендә нәтиҗәле эш алып бара. Бирегә йөрүче студентлар үз проектлары белән Россия күләмендә генә түгел, дөньякүләм мәйданда КФУ данын яклыйлар. Күптән түгел генә Вашингтонда үткән зур фәнни чарада алар тарафыннан тәкъдим ителгән «Җинаять суды моделе» җиңү яулый. Соңгы җиңүләренең берсе – студентларның һәр елны үткәрелә торган «Ел студенты -2016» республика конкурсында «Елның иң яхшы студентлар фәнни җәмгыяте» номинациясендә җиңүләре. Әлеге җәмгыять белән 2009 елдан бирле аны нигезләгән кеше, гамәли адвокат – **Лукин Юрий Михайлович** җитәкчелек итә.

Җәмгыятьнең үз структурасы: сайлап куелган рәисе, аның төрле юнәлешләр өчен җаваплы 10 урынбасары бар. Әңгәмәдәшем Лилия – җәмәгатьчелек белән эшләү өчен җаваплы урынбасар. Аның әйтүенчә, аларның һәрберсе универсаль кеше, үз эше өчен генә җавап бирүдән тыш та, һәр эшне булдыралар, бергәләшеп эшлиләр. Бәлки, әлеге җәмгыятьнең уңышлары да шуңа бәйледер?!

Юридик факультет студентлары фәнни җәмгыятенең уникаль проектлары байтак. Алар ел саен тиңдәше булмаган «Суд дебатлары»н үткәреп киләләр. Әлеге проект шулай ук «Ел студенты» республика конкурсының «Ел проекты» номинациясендә җиңүче булган иде. Бу проект турыдан-туры юридик практикага керәп китүе белән күпләрне кызыксындыра һәм аерылып тора. Уенга, экспертлар буларак, Казандагы гамәли хөкемдарлар гына түгел, кунаклар да чакырыла, мәсәлән, һәр елны Саратовтан киләләр икән. Баштагы чорда эш конституцион суд эше, гражданлык суды эше, җинаять суды эше кебек 3 юнәлештә алып барылса, үткән дебатларда социаль юнәлеш тә өстәлә. Бу исә башка юнәлештә укучы студентларга да катнашу мөмкинлеге бирә. Социаль сораулар – стипендия түләү, тулай торакка урнашу – һәркемне борчыган мәсьәләләр. Чыннан да, әлеге чарада башка институт, факультет студентлары да бик теләп катнашалар. Чөнки чакырылган тәҗрибәле гамәли юристлар бер генә мөрәҗәгатьне дә җавапсыз калдырмый. Тагын бер проект – «Юридик конвент» – 10 ел дәвамында уздырылып килгән Халыкара конференциянең дәвамы, яңа формасы. Ул да, гамәли мәсьәләләрне чишүгә юнәлдерелү сәбәпле, тиз популярлык ала.

Фәнни җәмгыять әгъзалары, үзләрендә генә кунаклар кабул итеп калмыйча, читтә үткерелә торган төрле фәнни-гамәли конференцияләрдә дә актив катнашалар. Һәр елны делегация белән Уфага – Башкорт

дәүләт университетына, Саратовка, Белоруссиягә, Дагыстанга баралар. Моннан тыш, институтара чаралар да оештыралар.

Юридик факультетның студентлар фәнни җәмгыятенә йөрүчеләрнең төгәл саны юк. Чөнки бу санга факультеттагы 30га якын фәнни түгәрәкләргә йөрүчеләрне дә кертеп исәпләргә кирәк. Түгәрәкләр саны да һәр елны үзгәреп тора. Кайберсе кушыла, ә кайберләре, аерылып, мөстәкыйльлекне сайлый. Гомумиләштереп әйткәндә, факультетның студентлар фәнни җәмгыяте 300гә якын студентны берләштереп тора.

**— Базар шартларында студентларны фән белән шөгыльләнергә ничек җәлеп итәсез?** — дип кызыксындым.

— Кайбер укытучылар җәмгыятебездә актив шөгыльләнүче студентларга автомат билге куя. Уңышларга ирешүчеләргә югары стипендия каралган. Оксфорд фонды стипендиясе алучылар да байтак. Финанс мотивациясеннән тыш, төрле алмашып уку программалары, стажировкалар да кызыксындыра безгә йөрүчеләрне. Магистратурага, аспирантурага керергә теләк белдерүчеләргә дә, мотивация буларак, фәнни мәкаләләрен, эшләрен төрле җыентыкларда бастыру мөмкинлеге зур, — ди әңгәмәдәшем Лилия Яфизова.

Моннан тыш, факультетта фәнни эш язу, алга таба фән белән шөгыльләнүнең перспективаларын күрсәткән ачык лекцияләр үтә икән. Ә нәтиҗәсе озак көттерми. Юрфак студентлары беренче курстан ук

*«Яшь галимнәргә ипотекасыз фатир бирер идем»*

үзләренең фәнни хезмәтләрен яза башлыйлар, ә практикага йөреп, теманы тирәнрәк өйрәнеп, хезмәтләренең бәһасен арттыралар. Техник өлкәдә фәнни ачышның нәтиҗәсе кулга тотып карый торган предмет ясау белән билгеләнсә, гуманитар өлкәдә ул, еллар үтеп, җәмгыятьнең уңай якка үзгәрә баруы белән генә үзен сиздерә башлый.

Белүебезчә, фән белән шөгыльләнү махсус шартлар таләп итә. Төгәл фәннәр өлкәсендә укучылар өчен ачышлар ясарга лабораторияләр булу кирәк. Лилия әйтүенчә, гуманитар өлкәдә укучыга фән белән шөгыльләнү өчен төп шарт — студентның үз фикере булу. Төрле кодекслар, юристлар фикере, суд практикасына күзәтүләр — алыштыргысыз инструментлар. Бу уңайдан хәзер көне буе китапханәдә кәгазь тузаны иснәп утыру да кирәкми. КФУ күп кенә дөньякүләм электрон ресурсларга керү мөмкинлеге бирә. Студентлар бигрәк тә «Гарант», «Консультант +» электрон хокук системаларыннан актив файдаланалар.

**— Фәнни эшләр кайчан языла: төнләме, көндезме?**

— Тынычлыкта, уйланып. Ләкин күп кенә студентлар ахырга кадәр сузып йөриләр. Еш кына дедлайн килеп җитәрәк кенә яза башлыйлар, — ди, борчылуын белдереп, Лилия. Ул үзе юриспруденциянең халыкара хокук юнәлешен сайлаган. Соңгы арада зур шау-шу тудырган Олимпиада, допинг вакыйгаларына бәйле рәвештә спорт хокукы мәсьәләләрен яктырткан фәнни эш язу белән мәшгуль.

Шулай җитди генә сөйләшеп утырганда, хыялларга бирелеп киттек. Лилиягә: «Әгәр тылсымчы булсаң, яшьләрне фәнгә тартуның тагын нинди юлларын булдырыр идең?» — дим.

*— Ел дәвамында фән белән ныклап шөгыльләнгән студентларга ял итәргә путевка, ә үзенең ачышын тормышка ашырган студентларга, яшь галимнәргә ипотекасыз фатир бирер идем,* — ди.

Юридик факультетның университетыбызда 12 ел дәвамында уңышлы, нәтиҗәле эш алып бара торган студентлар фәнни җәмгыятенең максаты изге — үзләреннән соң факультет, университет галимнәренең данлы эшен дәвам итүче лаеклы буын калдыру. Җәмгыятьтә йөрүчеләр арасында һәр курстан вәкилләр булуга карамастан, инде үзләренә алмаш әзерләү бурычы куелган. Ә яшь галимнәр сафына басу җиңел түгел. Иң-иңнәрен җәмгыять үткәргән төрле чараларда сайлап, сынап, актив катнашучыларны гына алалар. Үз фикерең булудан тыш, тәпле белем һәм оештыра белү сәләтенә дә ия булырга кирәк әле.

**Белми калма!**

# ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ «ТАВЫШЫ»

Соңгы арада татар гаммәви мәгълүмат чараларының билгеле бер тематик юнәлештә генә үсүе күзәтелә. Бу, нигездә, журналистларга мәгълүмат аз керүдән һәм яңалыкка омтылуга этәргеч булмаудан. Нәкъ менә шуңа күрә Бөтендөнья татар яшьләре форумы махсус проект тәкъдим итә: «Тавыш».

«Тавыш» медиа-лабораториясе ул – яшь татар журналистларын һәм блогерларын профессиональ яктан үстерү, белем бирү өчен махсус мәйдан. Медиа-лаборатория кысаларында махсус остаханәләр, белгечләр үткәрә торган семинарлар һәм интерактив форматтагы дәресләр булыр дип көтелә.

Әлеге проект белән кызыксынган һәркем тулырак мәгълүматны Бөтендөнья татар яшьләре форумының рәсми сайтыннан таба ала.



# «КОЕП КУЙГАН ГУМАНИТАРИЙ ИНДЕ МИН»

**Марсилә ФӘХЕРТДИНОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

СТУДЕНТ ТОРМЫШЫ КҮЗ АЧЫП ЙОМГАНЧЫ ҮТӘ ДӘ КИТӘ, ШУҢА КҮРӘ АНЫ ОНЫТЫЛМАСЛЫК ИТЕП ҮТКӘРЕРГӘ, КУЙГАН МАКСАТЛАРЫҢА ИРЕШЕРГӘ, ХЫЯЛЛАРЫҢНЫ ТОРМЫШКА АШЫРЫРГА ОМТЫЛЫРГА КИРӘК.

Сүземне юкка гына студентлар тормышыннан башламадым, һәр елны үткәрелә торган «Ел студенты – 2016» республикакүләм студентлар премиясен тапшыру тантанасы быел да шау-гөр килеп узып китте. «Шәхес» рубрикасының бүгенге кунагы – безнең штаттан тыш хәбәрчебез, әлеге тантананың бер номинациясе – «Ел журналисты» исеменә лаек булган кыз, татар журналистикасы кафедрасы студенты Регина Шиһабетдинова.

**– Регина, «Ел студенты» бәйгесе турында тулырак сөйләп кит әле…**

– Дөресен генә әйткәндә, минем бу бәйгедә катнашуым көтелмәгәндә генә килеп чыкты. Моңа алыныргамы-юкмы дип уйлаганым булды үзе. Шуннан инде төпле бер фикергә килдем. Бәйге ике этаптан торды. Аның берсе читтән торып үткәрелде. Журналистика өлкәсендәге эшчәнлегебез дәверендә җыелган бөтен материалларыбызны туплап, зур гына бер портфолио эшләп җибәрдек. Ә инде икенче турда безне жюри әгъзалары бәяләде. Анда шулай ук ниндидер үзгә бер визитка әзерләргә кирәк иде. Монда үзеңне журналист буларак та, шәхес буларак та күрсәтергә мөмкинлек булды.

**– Көндәшлектән курыктыңмы?**

Көндәшлек булуы ул әйбәт әйбер, ләкин мин монда беркемне көндәш итеп күрмәдем. Финалистлар арасында миннән күпкә тәҗрибәлерәк егетләр дә бар иде, алар арасында минем җиңеп чыгуым бер дә көтелмәгән хәл булды. Ләкин аның сөенече дә шуның белән артыграк.

**– Син нинди кеше?**

– Үзем турында бик үзгәрүчән кеше дип әйтер идем. Мәктәп чорында ул яхшы сизелә иде. Әллә ничә түгәрәккә йөреп караганым булды: бию, рәсем, баян, театр. Берсеннән генә читкә тайпылмадым: 11 ел буе нәфис сүз осталыгы белән шөгыльләндем. Студент тормышы башлангач, бөтен кызыксынуларымны журналистика алмаштырды. Бүген ул – һөнәрем дә, хобби да.

**– Журналистика өлкәсендә нинди эшчәнлек алып барасың?**

Мин «Татарстан» радиосында үземне радиожурналист буларак үстерәм. Басма матбугат өчен материаллар әзерлим. Социаль челтәрләрдә пабликлар, төркемнәр алып барам. Төрле оешмалар, чараларның матбугат хезмәтләрендә, үзәкләрендә эшләвемне дәвам итәм.

**– Илһамланырга нәрсә этәргеч бирә?**

–Илһам чыганагын мин үзем әзерли торган материаллардан эзлим. Шәхес, вакыйга һәм аларның җәмгыять өчен әһәмияте мине язарга этәрә. Һәр материалымда файдалы мәгълүмат булырга тиеш дигән максат – мена нәрсә илһамландыра мине. Кайчак әти-әнием, дустым яки танышым әйткән сүз, яхшы фильмнан калган тәэсир дә ярдәмгә килә. Характерлы нәрсә инде ул «илһам» дигәне: кайчак кирәкле сүзләр башка бик тиз килә, ә кайчак берничә көн буе яза алмый, уйланып йөрим дә, соңрак кына утырып язам.

**– Сиңа язу сәләте кайдан килгән дип уйлыйсың?**

– Сәләтемнең бер өлеше, һичшиксез, геннар аша бирелгәндер. Әти-әнием икесе дә һөнәрләре буенча мөгаллимнәр, эшләре генә башка. Икесе дә әдәбиятны ярата. Шуңа коеп куйган гуманитарий инде мин. Артык актив бала булганга, аралашырга бик яратам, кызыксынучанлыгым көчле. Җитмәсә, әнием – тележурналист, әтием – тикшерүче. Журналистикага туры юл алдан ук салынган булган икән бит, карале!



Елена Гредюшко фотосы

*Җәмгыятькә файда китерә алу мөмкинлеге, материалларыма кайтаваз булып яңгыраган җавап-фикерләр алга таба иҗат итәргә көч бирә*

**– Шигырьләр укырга яратасыңмы? Ниндиләрне?**

Мин шигырьләрне, укудан бигрәк, сөйләргә яратам. Сәхнәдән 3 ел элек төшсәм дә, кайчак барыбер тарта ул үзенә. Шигырьләрнең дә туган як, мәхәббәт, яшәү мәгънәсе, тарих турындагыларын үз итәм. Алар күңел кылларында рәхәтләнеп уйный, тетрәндерә, уйландыра.

**– Регина, бәхет нәрсә ул?**

– Бәхет – ул якыннарыңның исән булуын, гомумән, якын кешеләрең булуын, аларның сиңа ышанычы барлыгын, шул ышаныч биргән көч сине яхшы нәтиҗәләргә, биек үрләргә алып менгәнен аңлау.



Фото Илузә Кашапова архивыннан

# КЕШЕНЕҢ КӨЧЕ – ЭШЕНДӘ

Регина ШИҺАБЕТДИНОВА

**БӘЙРӘМ КИЛӘ, ДУСЛАР! ХЕЗМӘТ СӨЮЧЕ СТУДЕНТЛАРНЫҢ БӘЙРӘМЕ. 17 ФЕВРАЛЬ – РОССИЯНЕҢ СТУДЕНТ ОТРЯДЛАРЫ КӨНЕ.**

Бу вакыйганы билгеләп үтү 2015 елда Россия Президенты В.В.Путин имзалаган боерык буенча гамәлгә керде һәм узган елдан үткәрелә башлады. Ә студентларның хезмәт отрядлары тарихы күпкә бай. Беренче студент отрядлары илдә үз эшчәнлеген моннан 60 ел элек – ерак Казахстан җирләрен үзләштерүдән башлаган. 6 дистә ел эчендә бу хәрәкәт әллә ничә буынны тәрбияләгән.



2001-2016 елларда Татарстан отрядларында махсус урта һәм югары уку йортларында белем алган 135 меңнән артык студент хезмәт куйган. Бүген бу эшчәнлек республиканың Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Зәй, Бөгелмә һәм Чистай шәһәрләрендә актив үсеш ала. Ел саен студентларның хезмәт отрядлары составында 11 меңнән артык студент эш тәҗрибәсе туплый. Татарстан отрядлары Россиядә әйдәп баручылардан да санала икән.

Студентларны эшкә җибәргәндә барлыкка килә торган төп мәсьәләләр хакында безгә хезмәт отрядлары үзәгендә яшьләр эшләре буенча белгеч **Зилә Гыймазова** сөйләде. *«Студентларыбыз май аенда ук эшкә тотына. Димәк, сессияләрен аларга алданрак ябарга кирәк. Бу яктан безнекеләр бик уңган: укуда калышмыйча, тиз арада имтиханнарын да бирәләр, эшкә урнашып, җәй айларында акча да эшлиләр. Бу очракта уку йортлары да хәлләренә керә. Рәсми моментларны без тулысынча үз өстебезгә алабыз»*, – ди Зилә.

Безнең уку йортына килгәндә, Казан федераль университеты студентларының хезмәт отрядлары – ул студентларның ирекле берләшмәсе. Бу берләшмә эшчәнлегенең төп максаты: КФУда студент отрядлары хәрәкәтен үстерү. КФУда түбәндәге юнәлешләргә аеруча игътибар бирелә: педагогик отрядлар, проводниклар, төзелеш, геологик, сервис отрядлары һ.б. Күптән түгел авыл хуҗалыгы отрядлары да барлыкка килгән.



КФУның студентлар хезмәт отрядлары штабы 2011 нче елның февралендә университет администрациясе ярдәме белән барлыкка килгән. Совет чорында оештырылган студент отрядлары төзелеш, балалар һәм яшүсмерләр тәрбияләү, пассажирлар йөртү, авыл хуҗалыгы, халыкка хезмәт күрсәтү кебек эшләр башкарган булсалар, безнең уку йорты студентлары да, күпьеллык традицияләрне үзгәртмичә, аларны дәвам итә.

2016 нчы елда КФУның студентлар хезмәт отрядында 1021 студент эшләгән, аларның уртача хезмәт хакы 18500 сум тәшкил иткән.

Өстәвенә, студентларыбыз кайбер аерым юнәлешләрдә бөтен республика буенча яшьтәшләренең комиссарлары да булып тора. **Илузә Кашапова**, мәсәлән, Татарстанның проводниклар отрядлары комиссары. «*Үзебез төзегән «ФРЕШ» отрядының да комиссары булып торам әле мин. Безнең отряд 2 ел элек оешып, бүгенге көндә 20 студентны берләштерә. Алар Рәсәйнең төрле регионнарыннан җыелган булсалар да, безне КФУда уку берләштерә. Бергәләшеп 2 җәй һәм 2 кыш Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан – Мурманск, Анапа, Смоленск, Архангельск, Петрозаводск һ.б шәһәрләр юнәлешендә иң кызыклы, төшемле һәм күп хезмәт хакы түләнә торган эштә фидакарь һәм тырыш хезмәт куюыбыз белән чын күңелдән горурланабыз*»,– дип искәртте Илузә.

17 нче февраль – КФУ студентлар хезмәт отрядлары өчен зур бәйрәм. Әлеге тантаналы чара бик югары дәрәҗәдә оештырыла. Анда иң яхшы отрядлар игълан ителә һәм саллы бүләкләр белән билгеләп үтелә. «Darelfønyn» редакциясе студентларның хезмәт отрядлары вәкилләрен аларның бәйрәме белән котлый!

# Иске тарихка заманча караш

**Лилия ТУКТАРОВА,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

11 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫНЫҢ ЯҢА БИНАСЫНДА «ТАРИХИ БРАНЧ» КЛУБЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ АЧЫК ЛЕКТОРИЕ УЗДЫ.

«Тарихи бранч» — татар тарихына багышланган яңа форматтагы клуб. Очрашулар айга бер тапкыр, шимбә көнне иртәнге якта уздырыла. Тарих белән кызыксынучылар һәм аны тирәнтен өйрәнүчеләргә менә дигән мөмкинлек. Чара Бөтендөнья татар яшьләре форумы һәм Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан оештырыла.

Быел Бөек революциянең 100 еллыгы. Шул уңайдан, «Тарихи бранч»та «Татарлар һәм революция» темасы беренче итеп сайланды.

*«1917 ел һәм революциянең, гомумән, совет заманы вакыйгаларының татарларга тәэсирен аңлап бетермибез әле. Шул еллар тәэсире турында тәпле бер фикергә килеп булмый. Нәкъ менә шуңа күрә 1917 ел революциясе очрашуга этәргеч бирде»,* — диде КФУны тәмамлаган тарих фәннәре кандидаты, БТЯФ рәисе урынбасары **Айрат Фәйзрахманов**.

Аның чыгышы вакытында, һәркем 1917 елгы Казанга кайтып килгәндәй булды. Сез Ирек мәйданында басып торасыз, февраль ае нәкъ менә шунда башлана. Аннан соң Сынлы сәнгать музее кырына күчәбез. Биредә дә бик күп кызыклы вакыйгалар булган. Ул элек генерал һәм хәрби округның башлыгы Александр Сандецкий йорты иде. Карл Маркс урамы буенча юлны дәвам итәбез. Хәзерге Горький паркы якларына күчәбез. Шуның артында гына «Арча кыры». Биредә дә зур революцион вакыйгалар булган. Хәзер әлеге



Фотолар БТЯФ архивыннан

урыннар Николай Ершов урамы дип атала. Николай Ершов — Казанда Октябрь революциясендә актив катнашкан кеше. Ершовның «Казанны ике тапкыр яуладылар, беренче тапкыр аны явыз Иван яулады, ә икенче тапкыр мин яуладым» дигән сүзләре дә сакланып калган хәтта. Бераздан Кызыл Позиция урамына чыгабыз. Әлеге урам бик күп сугышлар һәм атышлар белән истәлекле. Нәкъ шушы урында Ершов һәм аның солдатлары октябрь революциясенә каршы кешеләргә һөҗүм иткән. Урам ташлары канкойгыч вакыйгаларны әле дә хәтерлидер сыман.

Көн дә шушы урамнардан йөрибез, ә тарихны, җанөшеткеч тарихны күпләребез белми.

«Тарихи бранч» борылышлар, тарихи вакыйгалар, шәхесләр, чорларны шәрехли һәм моңарчы катлаулы булып тоелган сорауларга җавап бирә. Алай гына да түгел, дистә еллар элек булган вакыйгаларга яңача караш яңгырый биредә. Клубка килгәннәргә академик текстлар укырга, хронология ятларга кирәк булмаячак. Лектор белән аралашу, видео һәм инфографика, Татарстан архивларында саклана торган документлар ярдәмендә дә тәпле һәм тирән белем алырга мөмкин.

***P.S.:*** *Ай саен бер шимбә иртәсен кәһвә һәм татар тарихына багышлагыз!*



12+
DARELFONUN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Р.Садретдинов, А.А.Абдрахманова
Корректор - Р.Ә.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – ФГАОУ ВО Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәширият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 334 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru
Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2016 елның 08 сентябрендә ПИ № ТУ 16-01506 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00, 15.02.2017. «Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюз ур., 17в.